*Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы*
*Муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе*
***Кодаш төп гомуми белем бирү мәктәбе***

***“Үз тамырларыңны хәтерләп яшәргә...”***
*III укучыларның фәнни тикшеренү - крайны өйрәнү эшләре*
*республикакүләм конференциясе*
***“Этнография”** номинациясе*

# *Эзләнү-тикшеренү эше*

# Тема: *Туган авылым – мирас сандыгы*
# *(Кодаш авылының гореф-гадәтләре, авыз иҗаты үрнәкләре)*

*Автор: Мингалимова Эльвина*
*Фәнис кызы, 25.01.1998, 9 нчы сыйныф,2014*

*Җитәкчесе: Җиһаншина Зилә Мәгъдәнур кызы*
*Кодаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең*
*музей җитәкчесе*

# Максат

**270 елга якын тарихы булган туган авылыбызның гореф-гадәтләрен , топонимикасын, авыз иҗаты үрнәкләрен өйрәнү һәм киләчәк буыннар өчен саклап калу**

# Бурычлар

**Өлкән буын кешеләре белән очрашып, музейны авылдашларыбызның иҗат җимешләре, гореф – гадәтләре турындагы материаллар белән тулыландыру;**
**аларны берләштереп, тематик альбомнар төзү һәм авылның 270 еллыгын бәйрәм иткәндә тәкъдим итү**

## ЭШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

*Авылдагы кеше исемнәрен өйрәнү*

*Авылыбызгы кагылышлы топонимнарны өйрәнү*

*Авылда саклаланган гореф – гадәтләрне өйрәнү*

*Авылдашларыбызның авыл иҗаты үрнәкләрен өйрәнү*

# Авылдагы кеше исемнәрен өйрәнү

| | | |
|---|---|---|
| *1920-1950 нче еллар* | *Революциягә кадәр, ислам дине көчле чакта үтеп кергән һәм сакланып калган исемнәр ; кешенең йөз һәм холкын күрсәтүче күркәм сыйфатларны белдерүче* | *Сөнгатулла (аллаһ һөнәре)-9, Хөснулла (аллаһның күркәмлеге) -6, Сажидә (баш июче)-10, Саимә (ураза тотучы) —7 һ.б. Әнисә ( якын дус )-8, Шәмсия (кояш кебек )-5, Кәрим (газиз, кадерл) -6, Камал ( камил) тамыры белән- Шәмсекамал, Сәрбикамал, Минкамал, Нурлыкамал һ.б.* |
| *1960-1980 нче еллар* | *Рус теленнән һәм рус теле аша көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәр* | *Марат, Марс, Альберт, Венера, Флера, Роза һ.б* |
| *2000-2010 нчы еллар* | *Бик матур, мәгънәле татар исемнәре* | *Әлфия, Айсылу, Айгөл, Нияз, Азат, Алмаз, Айназ, Таңсылу, Илүзә, Алсу һ.б* |

# Авылыбызга кагылышлы топонимнарны өйрәнү










Чишмәле булак


Очлы тау


Сулы чокыр


Чат тавы



Кичләрен чишмә буенда кичке уеннар оештырганнар. Яшь киленнәрне су юлы күрсәтергә шунда алып килгәннәр. Алар анда киләчәктә матур тормыш корырга вәгъдә бирешкәннәр. Бу чишмәнең агышы да ничектер серле кебек тоела.

# Хыял чишмәсе




Яшьләр урамы


Пионер урамы


Совет урамы


Муллагали урамы


Таң урамы

# Авылда сакланган гореф – гадәтләрне өйрәну

**Авыл тарихына күз салсак, күп кенә гореф-гадәт, йола-бәйрәмнәр тарихта бик авыр чорлар булуга карамастан сакланып калган. Болар – балага исем кушу, сөннәткә утырту, кызыл туй, мәет күмү, сабантуй бәйрәмнәре. Әмма күп кенә борынгы бәйрәмнәребез онытылган.**

**Нәкъ менә сугым суйган көнне, Аллаһка биргән ризыклары өчен рәхмәт әйтү йөзенән, һәр өйдә коръән укытыла торган булган. Бу йола хәзерге көндә юк дәрәҗәсендә.**

**Безнең мәктәптә халкыбызның рухи хәзинәсен торгызу буенча күп кенә эшләр эшләнә. Аулак өй, Сөмбелә, Нәүрүз, Карга боткасы бәйрәмнәрен үткәрү традициягә әйләнде.**













***“... безнең халык – шигырь вә җыр, бәет чыгарырга бик маил (һәвәс) халык”***

***Габдулла Тукай***

# Авылдашларыбызның авыз ижаты үрнәкләрен җыю







Җырлар

1. Сагынмамын дигән идем,
Сагынамын үзеңне.
Йөрәгемнең саф җирендә
Саклыйм әйткән сүзеңне.

2. Яратамын үзеңне,
Магнитлы күзеңне.
Телефонда бер кош күрдем,
Шуңа охшатам үзеңне.

3. Ал юдым елгаларда,
Гөл юдым елгаларда.
Аерылудан авыр хәлләр
Юк икән дөньяларда.

4. Ишек алдым яшел чирәм,
Таптатма, әнкәй, киртә тот.
Үз кулларыңда иркә тот,
Ятка киткәч үпкә юк.

Бу җырлар 1914нче елгы Зәйтүнә әби Габса...
язып алынды.



16. Биек тауның башларында
Каеннар яфраксыз.
Бу илләрдә кошлар гына
Кайгысыз, хәсрәтсез.

17. Агыйделкәйнең буйларын
Сандал киеп буйлама.
Син сөймәсәң, мин дә сөймим,
Ялынып дип уйлама.

18. Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем төрлесен.
Уйлама күңелем төрлесен
Әллә ниләр күрерсең.

19. Урал елгалары борылып ага,
Ул ярата борылып агарга.
Мин ярата идем ерак фронтларга
Сагынып сәлам хатлар язарга.

20. Күндезләрен уйлап йөримен дә
Төнлә төшләремдә күрәмен.
Төшләремдә боек күренәсең,
Кайталмавың шуны күрәмсең.

21. Әнкәй дә каргагандыр,
Әткәй дә каргагандыр.
Ике каргыш бергә килеп
Бәхетемне каплагандыр.

22. Сандугачым сайрап җибәр,
Моңлы тавышың белән.
Мин дә сиңа кушылырмын
Моңлы тавышым белән.

23. Ялгыз каен, ялгыз каен.
Ялгыз каен кырларда.
Ялгыз каеннардан ялгыз
Мин бүгенге көннәрдә.



Безнең урам аркылы
...а суның салкыны.
...лкын сулар гына басмас
...ган йөрәк ялкынын.

Кара атка килешә
...ра дуга, дилбегә.
...рыбер тормам бу илләрдә
...авышым калсын билгегә.

Аргы якның аланы,
...ы була баланы.
...та-ана үстерә икән
...срәт өчен баланы.

Аккош аталар микән,
...пен саталар микән?
...хетсез булган балага
...хет саталар микән?

12. Мин бәхетсез, мин бәхетсез,
Мин бәхетсез булганмын.
Әнкәемнең иң кайгылы
Көннәрендә туганмын.

13. Урман буйлары томан ла,
Урман буйлары томан.
Шул томаннар арасында
Сез дусларым бар сыман.

14. Алма ашыйлар, алма ашыйлар,
Алманың ни туклыгы?
Бәхетлеләр рәхәт яши,
Ай бәхетемнең юклыгы.

15. Күрсенмәгез, күрсенмәгез,
Күрсенмәгез, күп тормам.
Айлар торсам, еллар тормам,
Сагынсагыз да булмам.







- 1 -

Исәнмесез әбей, туганнарым
Әти-әнием, бердән-бер апам
Сез күңелдән кайнар сәлам йөтеп
Барыгызга да хат язам атап
Белгәне, сез бәлки шикләнмәгез
Түбәндәге язган сүзләргә
Сезнең янда чакта курка идем
Ә хәзер мин телим сөйләргә.
Үзем дә мин хәзер шиша алмыйм
Башымнан үткән чакта бу хәлгә
„Ул бер" мәңгә әллә нәрсә булды,
Күзгә күренү, әллә бер хәлдә!
Белсә нечек аңлагыз сез,
Кичкен уттә минем баштан ул
Булган хәлне дөрес башламадым
Тукта инде „сөйлим баштан ук.
Июнь башы, көзме баеп бара
Нурлары аның тулы сәтиннан
Тузоклыкка карап саф һавага
Жәй кайткан Карабаш читеннан.
Туган якның матурлыгын,
Күрә белми икән кем генә
Нигәр булса да ул башка жирдән
Бөтен жирдә курка күрен.
Дөрес, туган якның матурлыгын
Аның һәрбер кеше үзенгә,
Әле, бәлки хаклы түгелмендер,
Тик мин аклыйм аны үземчә.
Үз жирендә аяк басу белән,
Экилмтәгегә үзгәрем
Бала чаклар кинәт искә төшә
Чиклап милай сулам, ашарам.
Туры киләдә нигә шаккыр кетеп
Туган жиргә кабат кайтырга
Кайткан саен әйтеп бетергесез
Чуклыкланы, шатлык таттырга.
Бу юлы да кайтуым уз авылыма
Аһир тәүге, авыр хис белән,
Изтәр итеп мин хакаган кердем
Үз-үземне рухи көч белән.

- 2 -

Бөтен буыннарым йомшарды
Күз алларым томан каплады.
Әмь агачка ике куллап ябышып
Җиргә егылудан саклангдым.
Калкып чыкты шарда Зинфира апам
Әзгәр костынкаеп куенда
Ак дисемнерын кигән, тулы йөзле
Чиксез сагыш аның йөзендә.
„Саулы әнем", кайтаңдамы инде
Язган хатларымны син алдыңмы?
Ник язмадың шабан хаты миңа.
Әллә инде хәтерең калдыммы?
Куркма син, кагылмам мин сиңа
Аңа китмәм үзем белән дә
Озак шатпкарлап та торман сине
Рәхмәт, килеп хәлне белгәнгә.
Килдәсенә кәтен тәрдем бүген
Бәйрәм киемнәрен киенен
Жир күтәрми йөрәк серен минем
Сөйләргә дип чыктым шәленнән.
Май ахыры иде, матур көннәр
Тайгачыннан иң үзәл чоры
Якты көннең саф һавасын сулап
Тынычта йөри бөтен карт-коры...
Тәрәз аша ишеттелеп тормын
Яңа ярган яфрак шаулавы
Таза сау-сәламәт кешеләрнең
Көр сөйләшеп тышта йөргәне.
Ә мин мәҗбүр булдым больницада
Бер бүлмәдә ялгыз ятарга
Әнкә әтиләнә куллар кысылса да
Әтиен жирән үйгә батарга.
Әйтмәдем мин әти-әниләргә
Үз хәлемнең авыр икәнен
Сызлыгының минем йәнгә кигән
Ахырга да һич белгертмәдем.







# Кулланылган әдәбият

1.Асылов Д. “Исем -атамаларда да хикмәт бар”, Бөгелмә авазы”газетасы, № 82,83,86,89,90,92,1994 нче ел.

2. Гарипова Ф. “Авылларны сөям җаным-тәнем белән”, Казан,1994

3. Гарипова Ф.”Исемнәрдә ил тарихы”, Казан, 1994

4.“Еллар, язмышлар...”, 1997

5.“Кодашым- изге җирем”, 1997

6. Рәхимов Җ. “ Бөгелмә төбәге авыллары тарихы”, “Бөгелмә авазы”газетасы, № 179 (29.07.2009), 192-196 (14.08.2009)

7.Саттаров Г.Ф. “Мәктәптә туган як ономастикасы”, Казан, 1984

8.Саттар –Мулилле Гомәр.”Татар исемнәре ни сөйли”, Казан, 1998